**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге составына керүче Вольнистан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

26.11.2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Вольнистан авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту , торак пункт территориясен төзекләндерү: кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү). өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 248 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 233 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 125 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге составына керүче Вольнистан авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Вольнистан авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту , торак пункт территориясен төзекләндерү: кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү). өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Вольнистан авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________ Р.Ә. Җамалтдинов

Янтуган авыл җирлеге

башлыгы ___________________ Р.Ә. Җамалтдинов